Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Зур Мәшләк авыл җирлеге составына керүче
Бикчурай авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

18 ноябрь 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елнын 18 ноябрендә түбәндәге сораулар буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:
“Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең Бикчурай авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, 1 нче группа инвалидлардан, махсус хәрби операцияда катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, торак пунктта теркәлгән, әмма теркәү урыны буенча 5 елдан артык яшәмәүче гражданнардан гайре ) 600 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:
Бикчурай торак пункты территориясендә

– урамнарны яктырту җайланмалары урнаштыру;
_ су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аларны чистарту, халыкка су бирүне (җибәрүне) тәэмин итүче суэтем башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын, су белән тәэмин итү һәм субүлү системаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
_ торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 153 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 126 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
“ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 120 кеше тавыш бирде;
“ЮК» позициясе өчен җыенда катнашучы 6 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге составына керүче Бикчурай авылында гражданнар җыенын үткән дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.
2. Гражданнар җыенына куелган түбәндәге сорауны кабул ителгән дип расларга: Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең Бикчурай авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, 1 нче группа инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, торак пунктта теркәлгән, әмма теркәү урыны буенча 5 елдан артык яшәмәүче гражданнардан гайре ) 600 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга:
Бикчурай торак пункты территориясендә

- урамнарны яктырту җайланмалары урнаштыру;
- су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аларны чистарту, халыкка су бирүне (җибәрүне) тәэмин итүче суэтем башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын, су белән тәэмин итү һәм субүлү системаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авылы, Школьная урамы, 13А йорт; Югары Мәшләк авылы, Нариманова урамы, 24а йорт; Бикчурай авылы, М.Горький урамы, 50 А йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Шамсев Шәмсевәлиев М.М.

Зур Мәшләк авыл җирлеге
башлыгы вазыйфаларын башкаручы : Шәмсевәлиев М.М.